# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең Колаңгы станциясе поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2021 елның 25 ноябрь** **№1**

2003 елның 6 октябрендэге 131 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 23 ноябрендэ 14 сәгать 00 минут , 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минут, 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минут гражданнар җыены нәтиҗәсе белән «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Колаңгы станциясе торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:

- җирлектэге торак пунктлардагы санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып балалар мәйданчыгын төзекләндерү;
- урам яктырткычларын ремонтлау, материаллар сатып алу;

*б) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм ремонтлау, материаллар алу;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак – пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 262 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 163 кеше, тавыш бирүдә катнашкан кешеләр саны 60.0% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә

бүлендә:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 163 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең Колаңгы станциясе торак пунктында гражданнар җыенын халык җыены нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2."Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Колаңгы станциясе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:

- җирлектәге торак пунктлардагы санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып балалар мәйданчыгын төзекләндерү;
- урам яктырткычларын ремонтлау, материаллар сатып алу;

*б) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм ремонтлау, материаллар алу;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак – пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче** **Ф.Т. Нигматзянов**
**Колаңгы авыл җирлеге башлыгы**